**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕШЕМЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ШӘМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

422374 с. Большое Шемякино ул.Кутузова д.1

422374 Олы Шәмәк авылы,
Кутузова урамы,1

тел. (84373) 56-6-48, факс 56-6-48тел. , e-mail: Bsmk.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606556938, ИНН/КПП 1638001529/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**20 .12. 2024** **№ 5**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОЛЫ ШӘМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНА КЕРГӘН ГРАЖДАННАР МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРЕНӘ АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлеге Советына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **А.И. Афанасьев**